**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

«26» май 2025 ел № 129

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 117 номерлы карары белән расланган Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 12 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында», 92-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 28 апрелендәге №02-08-02-2025/Прдп208-25 протесты нигезендә, Кышлау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 117 номерлы "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында" карары белән расланган Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.9 пунктында "2025 елның 1 гыйнварына" сүзләрен "2028 елның 1 гыйнварына" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 16 бүлекнең 16.10 пунктындагы 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Кашшапов А.Х.